# С О Г Л А Ш Е Н И Е
## о торгово-экономическом, научно-техническом и социально-культурном сотрудничестве между Республикой Татарстан и городом Москвой

Республика Татарстан в лице Президента Республики Татарстан Минниханова Рустама Нургалиевича, действующего на основании Конституции Республики Татарстан, с одной стороны и город Москва в лице Мэра Москвы Собянина Сергея Семеновича, действующего на основании Устава города Москвы, с другой стороны, именуемые в дальнейшем «Стороны»,

основываясь на взаимной заинтересованности в сохранении и расширении двусторонних связей на стабильной и долгосрочной основе в торгово-экономической, научно-технической, социальной, культурной и иных областях,

желая создать соответствующие организационные, экономические, правовые и иные необходимые условия для укрепления межрегионального сотрудничества,

учитывая необходимость осуществления практических действий, направленных на социально-экономическое развитие обоих субъектов Российской Федерации,

стремясь обеспечить эффективное взаимодействие исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан и города Москвы во всех сферах социально-экономической деятельности, заключили настоящее Соглашение о нижеследующем:

### Статья 1

Стороны осуществляют взаимодействие и сотрудничество в соответствии с Конституцией Российской Федерации, законодательством Российской Федерации, законодательством Республики Татарстан и законодательством города Москвы.

Стороны строят и развивают свои отношения, исходя из принципов доверия, равноправия, взаимного уважения, партнерства, взаимной экономической выгоды и обоюдной ответственности за выполнение положений настоящего Соглашения и достигнутых на его основе договоренностей.

Стороны заблаговременно информируют друг друга о решениях, принятие которых затрагивает права и законные интересы другой Стороны, а также воздерживаются от действий, которые могут нанести экономический или иной ущерб другой Стороне.

Стороны считают, что в осуществлении сотрудничества могут принимать участие любые организации, независимо от их организационно-правовой формы и формы собственности, а также органы местного

самоуправления, находящиеся на территориях Сторон, в пределах их компетенции и на основе соответствующих договоров, соглашений или протоколов.

**Статья 2**

Стороны согласовывают свои позиции при рассмотрении проектов федеральных конституционных законов, федеральных законов и иных нормативных правовых актов Российской Федерации в части соблюдения в них конституционных прав и законных интересов Республики Татарстан и города Москвы и их жителей.

Стороны осуществляют обмен информационно-методическими материалами по вопросам законотворчества, базами данных по нормативным правовым актам Республики Татарстан и города Москвы.

**Статья 3**

Стороны создают благоприятные условия для обмена научно-технической, экономической, правовой и иной информацией, в том числе информацией по порядку ведения реестра государственной собственности, прогнозным продовольственным балансам спроса и предложения, активно содействуют расширению связей между исполнительными органами государственной власти, органами местного самоуправления и хозяйствующими субъектами в областях экономики, инвестиций и инноваций, торговли и промышленности, в том числе машиностроения, легкой промышленности, топливно-энергетического и нефтехимического комплекса, строительства и архитектуры, агропромышленного комплекса, развития малого и среднего предпринимательства, высоких технологий, информатизации, охраны окружающей среды и природопользования, связи, транспорта, здравоохранения, образования, науки, культуры, молодежной и семейной политики, спорта, туризма, безопасности населения и обеспечения правопорядка, борьбы с преступностью, а также в сфере реализации приоритетных национальных проектов.

**Статья 4**

Стороны содействуют установлению, сохранению и расширению торгово-экономических связей между хозяйствующими субъектами, расположенными на территории Республики Татарстан и города Москвы.

Стороны создают благоприятные экономические, финансовые и правовые условия для предпринимательской или иной хозяйственной деятельности организаций всех форм собственности, расположенных на территории Республики Татарстан и города Москвы, а также для инвестирования в производство, представляющее взаимный интерес.

Стороны разрабатывают и реализуют совместные проекты,

направленные на развитие экономики Республики Татарстан и города Москвы, проводят обмен проектами и специалистами по отраслям, представляющим взаимный интерес.

Стороны способствуют осуществлению взаимных поставок необходимых видов продукции производственно-технического назначения и потребительских товаров, определению экономических и финансовых возможностей организаций, расположенных на территориях Республики Татарстан и города Москвы, с целью выбора наиболее оптимальных партнеров в хозяйственной деятельности.

Для достижения указанных целей Стороны обмениваются экономической информацией, сведениями о потребностях Республики Татарстан и города Москвы в продукции (работах, услугах), приглашают организации, расположенные на территории другой Стороны, к участию в проводимых выставках, ярмарках, а также в различных форумах, семинарах, конференциях и иных мероприятиях, содействуют организации рекламы услуг и продукции, производимой (представляемой) хозяйствующими субъектами другой Стороны.

Стороны оказывают содействие друг другу в осуществлении внешнеэкономических связей.

**Статья 5**

Стороны сотрудничают в сфере разработки, освоения и развития наукоемких производств и технологий, наиболее перспективных направлений и совместных научных тем, имеющих практическое значение, в том числе связанных с диверсификацией промышленного производства, а также информационно-телекоммуникационными технологиями.

Стороны создают благоприятные условия для всесторонних контактов участников научной деятельности Республики Татарстан и города Москвы, включая их участие в обмене опытом, научной информацией, научно-исследовательскими и опытно-конструкторскими разработками в различных отраслях, и других формах сотрудничества.

Стороны содействуют привлечению научно-исследовательских и других организаций к разработке совместных проектов и программ, направленных на развитие Республики Татарстан и города Москвы.

**Статья 6**

В сфере социально-культурного сотрудничества Стороны участвуют в разработке и реализации совместных программ в области:

- развития трудовых отношений, в том числе охраны труда, экспертизы условий труда, социального партнерства, развития персонала и обеспечения рынка труда квалифицированными кадрами;

- поддержки семьи, материнства, детства, молодежи, людей старшего поколения и инвалидов, профилактики безнадзорности и правонарушений

несовершеннолетних, работы центров реабилитации, адаптации детей-инвалидов в Республике Татарстан и городе Москве;

- взаимодействия с национально-культурными автономиями, общественными и религиозными организациями и объединениями;

- образования, в том числе оказывают взаимное содействие в подготовке кадров, в повышении квалификации, разработке и совершенствовании образовательных программ с использованием профильных учреждений и научного потенциала Республики Татарстан и города Москвы, создают условия обмена передовым опытом в части изучения татарского языка, новыми информационными и педагогическими концепциями и технологиями между учреждениями образования Республики Татарстан и города Москвы, для чего Стороны создают условия для обмена делегациями работников образования, организации выездных семинаров, конференций, проведения совместных конкурсов и олимпиад в целях выявления одаренной молодежи, обмена делегациями и туристско-экскурсионными группами учащейся молодежи;

- здравоохранения, в том числе содействуют развитию связей между лечебно-профилактическими учреждениями Республики Татарстан и города Москвы, производят обмен опытом работы по совершенствованию организации лечебно-профилактической помощи населению, реализации федеральных и региональных целевых программ по охране здоровья и профилактике заболеваний, обмен информацией о состоянии рынка медицинской техники, лекарственных препаратов и иных изделий медицинского назначения, о возможностях их взаимовыгодных поставок, о достижениях в области теории и практики здравоохранения, предусматривая возможность совместных научно-прикладных исследований;

- культуры, в том числе содействуют проведению гастролей театрально-концертных коллективов, музейных выставок, библиотечных мероприятий, книжных выставок на основе прямых связей учреждений культуры, сотрудничают в осуществлении научно-методической работы в области детского эстетического воспитания, обмена детских творческих коллективов с проведением мастер-классов при участии ведущих специалистов-педагогов Республики Татарстан и города Москвы;

- физической культуры и спорта, в том числе способствуют участию спортсменов и спортивных команд Республики Татарстан и города Москвы в совместных спортивно-массовых мероприятиях, проведению совместных учебно-тренировочных сборов, приглашению тренерских кадров для участия в семинарах и курсах по повышению квалификации, обмену спортивными делегациями по отдельным видам спорта, а также опытом работы с детьми и подростками по месту жительства, развивают контакты и связи в области физической культуры и спорта;

- туризма, в том числе способствуют продвижению туристского потенциала друг друга на внутренний и международный рынки, содействуют развитию и расширению деловых связей между организациями в сфере туризма, расположенными на территориях Сторон;

- безопасности населения и охраны правопорядка, в том числе осуществляют обмен опытом по вопросам защиты населения и территорий от чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера, противопожарной безопасности, оказывают взаимную помощь в ликвидации последствий аварий, катастроф и стихийных бедствий; осуществляют обмен информацией о состоянии оперативной обстановки, сотрудничают в сфере борьбы с преступностью, в том числе коррупцией, терроризмом, незаконным оборотом наркотических и психотропных веществ, незаконными операциями с оружием, боеприпасами, взрывчатыми, ядовитыми и радиоактивными веществами, взаимодействуют при выявлении и ликвидации организованных преступных формирований, имеющих межрегиональные связи.

**Статья 7**

Настоящее Соглашение является основой для разработки и реализации двусторонних программ, протоколов и планов мероприятий, а также соглашений в конкретных областях сотрудничества.

По мере необходимости для организации и координации взаимодействия Сторонами могут создаваться рабочие группы, советы, комиссии.

Совместная деятельность Сторон по реализации настоящего Соглашения осуществляется путем проведения двусторонних консультаций, рабочих встреч, выставок, ярмарок, семинаров, конференций и иных мероприятий.

Для содействия в осуществлении положений настоящего Соглашения, а также контроля за ходом реализации соглашений (протоколов), заключенных (подписанных) Сторонами на его основе, может быть образован постоянно действующий координационный орган. Кроме того, по мере необходимости могут проводиться двусторонние консультации или переговоры, в том числе на высшем уровне.

**Статья 8**

Настоящее Соглашение не затрагивает обязательств каждой из Сторон по заключенным ими соглашениям (договорам) с третьими сторонами и поэтому не может служить препятствием для выполнения ими взятых на себя обязательств перед третьими сторонами.

Возможные расхождения в толковании и применении положений настоящего Соглашения или в понимании пределов его действия, спорные вопросы и разногласия, возникающие в ходе реализации, подлежат разрешению путем консультаций или переговоров Сторон.

**Статья 9**

Стороны признают, что Договор между Республикой Татарстан и

городом Москвой о принципах сотрудничества в экономической, научно-технической и культурной областях от 11 июня 1996 года прекращает свое действие со дня вступления в силу настоящего Соглашения.

**Статья 10**

Настоящее Соглашение вступает в силу с момента подписания и действует в течение 5 лет. Если ни одна из Сторон письменно не уведомит другую Сторону о прекращении действия Соглашения до истечения его срока, то Соглашение автоматически пролонгируется на один год.

Соглашение может быть расторгнуто в любое время в период его действия по взаимной договоренности Сторон, выраженной в письменной форме. Соглашение будет считаться расторгнутым по истечении 3 месяцев после письменного уведомления одной из Сторон о прекращении его действия.

Настоящее Соглашение может быть дополнено и изменено по взаимному согласию Сторон дополнительными соглашениями. Все изменения и дополнения к настоящему Соглашению действительны, если они совершены в письменной форме и подписаны полномочными представителями Сторон.

Совершено «12» марта 2011 года в городе Казани в двух экземплярах, каждый на русском и татарском языках, по одному экземпляру для каждой из Сторон, имеющих одинаковую юридическую силу.

| | |
|---|---|
| **За Республику Татарстан** | **За город Москву** |
| **Президент Республики Татарстан** | **Мэр Москвы** |
| _______ **Р.Н. Минниханов** | _______ **С.С. Собянин** |

12.03.2011

№ 77-490

18.03.2011

**Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында**

# КИЛЕШҮ

Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Президенты Миңнеханов Рөстәм Нургали улы йөзендә Татарстан Республикасы, бер яктан, һәм Мәскәү шәһәре Уставы нигезендә эш итүче Мәскәү шәһәре Мэры Собянин Сергей Семенович йөзендә Мәскәү шәһәре, икенче яктан, алга таба «Яклар» дип аталып,

сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль, мәдәни һәм башка өлкәләрдә тотрыклы һәм озак вакытка исәпләнгән элемтәләрне саклауга һәм киңәйтүгә үзара кызыксынуга таянып,

төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту өчен тиешле оештыру, икътисадый, хокукый һәм башка кирәкле шартлар булдырырга теләп,

Россия Федерациясенең ике субъектының да социаль-икътисадый үсешенә юнәлтелгән гамәли эшчәнлекне тормышка ашыру зарурлыгын исәпкә алып,

Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре дәүләт хакимияте башкарма органнарының социаль-икътисадый эшчәнлекнең барлык өлкәләрендә нәтиҗәле үзара хезмәттәшлеген тәэмин итәргә омтылып, әлеге Килешүне түбәндәгеләр турында төзеделәр:

## 1 статья

Яклар үзара эшчәнлекне һәм хезмәттәшлекне Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм Мәскәү шәһәре законнары нигезендә тормышка ашыралар.

Яклар үз мөнәсәбәтләрен ышаныч, тигез хокуклылык, үзара хөрмәт, партнерлык, үзара икътисадый файда һәм әлеге Килешү нигезләмәләрен һәм аның нигезендәге ирешелгән килешүләрне үтәү өчен ике яклы җаваплылык принципларыннан чыгып төзиләр һәм үстерәләр.

Яклар бер-берсенә кабул ителүе икенче Якның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагыла торган карарлар турында хәбәр итәләр, шулай ук икенче Якка икътисадый яисә башка зыян китерергә мөмкин булган гамәлләрдән тыелып калалар.

Яклар хезмәттәшлекне тормышка ашыруда аларның оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә теләсә нинди оешма, шулай ук Яклар территорияләрендә урнашкан җирле үзидарә органнары үз компетенцияләре чикләрендә һәм тиешле шартнамәләр, килешүләр яисә беркетмәләр нигезендә катнаша ала, дип саный.

**2 статья**

Яклар аларда Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре һәм аларда яшәүчеләрнең конституциячел хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау өлешендә федераль конституциячел законнар, федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары проектларын караганда үз позицияләрен килештерәләр.

Яклар законнар чыгару мәсьәләләре буенча мәгълүмати-методик материаллар, Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре норматив хокукый актлары буенча белешмәләр базалары белән алмашалар.

**3 статья**

Яклар фәнни-техник, икътисадый, хокукый һәм башка мәгълүмат, шул исәптән дәүләт мөлкәте реестрын алып бару тәртибе, ихтыяҗ һәм тәкъдим фаразланучы азык-төлек баланслары буенча мәгълүмат алмашу өчен уңай шартлар тудыралар, дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары һәм хуҗалык итүче субъектлар арасында икътисад, инвестиция һәм инновация, сәүдә һәм сәнәгать, шул исәптән машина төзелеше, җиңел сәнәгать, ягулык-энергетика һәм нефть химиясе комплексы, төзелеш һәм архитектура, агросәнәгать комплексы, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү, югары технологияләр, мәгълүматлаштыру, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану, элемтә, транспорт, сәламәтлек саклау, мәгариф, фән, мәдәният, яшьләр һәм гаилә сәясәте, спорт, туризм, халык иминлеге һәм хокук тәртибен тәэмин итү, җинаятьчелеккә каршы көрәшү өлкәләрендә, шулай ук өстенлекле милли проектлар өлкәсендә багланышларны киңәйтүгә актив булышлык итәләр.

**4 статья**

Яклар Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре территорияләрендә урнашкан хуҗалык субъектлары арасында сәүдә-икътисадый багланышлар урнаштыруга, аларны саклауга һәм киңәйтүгә булышлык итәләр.

Яклар Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре территорияләрендә урнашкан милекнең барлык рәвешләрендәге оешмаларның эшкуарлык яисә башка хуҗалык эшчәнлеге өчен, шулай ук үзара мәнфәгатьтәге призводствога инвестицияләр кертү өчен уңайлы икътисадый, финанс һәм хокукый шартлар тудыралар.

Яклар Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре икътисадын үстерүгә юнәлтелгән уртак проектлар эшли һәм гамәлгә ашыра, үзара мәнфәгатьтәге тармаклар буенча проектлар һәм белгечләр алмаша.

Яклар җитештерү-техник билгеләнештәге продукциянең һәм куллану товарларының кирәкле төрләре белән үзара тәэмин итүне тормышка ашыруга, хуҗалык эшчәнлегендә иң оптималь партнерларны сайлау максатларында, Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре

территорияләрендә урнашкан оешмаларның икътисадый һәм финанс мөмкинлекләрен билгеләүгә ярдәм итәләр.

Күрсәтелгән максатларга ирешү өчен Яклар Татарстан Республикасының һәм Мәскәү шәһәренең продукциягә (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) булган ихтыяҗлары турында икътисадый мәгълүмат, белешмәләр алмаша, икенче Як территориясендә урнашкан оешмаларны үткәрелүче күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә, шулай ук төрле форумнарда, семинарларда, конференцияләрдә һәм башка чараларда катнашырга чакыралар, икенче Якның хуҗалык итүче субъектлары җитештерүче (күрсәтүче) хезмәтләрне һәм продукцияне рекламалау оештыруга булышлык итәләр.

Яклар тышкы икътисадый элемтәләрне тормышка ашыруда бер-берсенә ярдәм итешә.

## 5 статья

Яклар фәнне күп кулланучы производстволар һәм технологияләр эшләү, үзләштерү һәм үстерү, иң перспективалы юнәлешләр һәм гамәли әһәмияткә ия булган уртак фәнни темалар, шул исәптән сәнәгать җитештерүен диверсификацияләү, шулай ук мәгълүмати-телекоммуникацион технологияләр белән бәйле темалар өлкәсендә хезмәттәшлек итә.

Яклар Татарстан Республикасының һәм Мәскәү шәһәренең фәнни эшчәнлектә катнашучылары, аларның төрле өлкәләрдә тәҗрибә уртаклашуда, фәнни мәгълүмат, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләре өлкәсендә катнашуын да кертеп, багланышлары өчен һәм хезмәттәшлекнең башка рәвешләрендә һәрьяклы уңай шартлар тудыра.

Яклар фәнни-тикшеренү һәм башка оешмаларны Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре үсешенә юнәлтелгән уртак проектлар һәм программалар эшләүгә җәлеп итүгә булышлык итә.

## 6 статья

Социаль-мәдәни хезмәттәшлек даирәсендә Яклар түбәндәге өлкәләрдә уртак программалар эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашалар:

- хезмәт мөнәсәбәтләрен, шул исәптән хезмәтне саклау, хезмәт шартларын экспертизалау, социаль партнерлык, персоналны үстерү һәм хезмәт базарын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итүне үстерү;
- гаиләгә, ана булуга, бала булуга, яшьләргә, өлкән буын кешеләренә һәм инвалидларга ярдәм, балигъ булмаганнарның караучысыз калуларын һәм хокук бозуларын профилактикалау, Татарстан Республикасында һәм Мәскәү шәһәрендә инвалид балаларны реабилитацияләү, адаптацияләү үзәкләре эшенә ярдәм;
- милли-мәдәни автономияләр, җәмәгать оешмалары һәм дини оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек;

- мәгариф, шул исәптән Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре профильле учреждениеләрен һәм фәнни потенциалын кулланып кадрлар әзерләүдә, квалификацияне күтәрүдә, мәгариф программалары эшләүдә һәм камилләштерүдә булышлык итәләр, татар телен өйрәнү өлкәсендә алдынгы тәҗрибә алмашу, Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре мәгариф учреждениеләре арасында яңа мәгълүмати һәм педагогик концепцияләр һәм технологияләр алмашу өчен шартлар тудыралар, моның өчен Яклар мәгариф хезмәткәрләре делегацияләре белән алмашу, күчмә семинарлар, конференцияләр оештыру, сәләтле яшьләрне ачыклау максатларында уртак конкурслар һәм олимпиадалар уздыру, укучы яшьләр делегацияләре һәм туристлык-экскурсия төркемнәре алмашу өчен шартлар тудыралар;

- сәламәтлек саклау, шул исәптән Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре дәвалау-профилактика учреждениеләре арасында элемтәләрне үстерүгә ярдәм итәләр, халыкка дәвалау-профилактика ярдәме оештыруны камилләштерү буенча эш тәҗрибәсен, сәламәтлек саклау һәм авыруларны профилактикалау буенча федераль һәм төбәк максатчан программаларын гамәлгә ашыру тәҗрибәсен уртаклашалар, медицина техникасы, дару препаратлары һәм медицина билгеләнешендәге башка әйберләр базарының торышы, аларны үзара файдалы алмашу, уртак фәнни-гамәли тикшеренүләр мөмкинлеген күздә тотып, сәламәтлек саклау теориясе һәм практикасы өлкәсендә казанышлары турында мәгълүмат алмашалар;

- мәдәният, шул исәптән мәдәният учреждениеләренең турыдан-туры элемтәләре нигезендә театр-концерт коллективлары гастрольләре, музей күргәзмәләре, китапханә чаралары, китап күргәзмәләре уздыруга булышлык итәләр, балаларны эстетик тәрбияләү өлкәсендә фәнни-методик эшне тормышка ашыруда, Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәренең әйдәп баручы белгеч-педагоглары катнашында осталык класслары үткәреп, балалар иҗат коллективларын алмашуга булышлык итәләр;

- физик культура һәм спорт, шул исәптән Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре спортчыларының һәм спорт командаларының уртак спорт-массакүләм чараларында катнашуына, уртак өйрәнү-тренировка уздыруга, квалификацияне күтәрү буенча семинарларда һәм курсларда катнашу өчен тренер кадрларны чакыру, спортның аерым төрләре буенча спорт делегацияләре алмашу, шулай ук тору урыннары буенча балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү тәҗрибәсе алмашуга булышлык итәләр, физик культура һәм спорт өлкәсендә багланышларны һәм элемтәләрне үстерәләр;

- туризм, шул исәптән эчке һәм тышкы базарларда бер-берсенең туристлык потенциалын алга җибәрергә ярдәм итәләр, Яклар территорияләрендә урнашкан туризм өлкәсендәге оешмалар арасында эшлекле элемтәләрне үстерүгә һәм киңәйтүгә булышлык итәләр;

- халык иминлеге һәм хокук тәртибен саклау, шул исәптән халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгынга каршы куркынычсызлык мәсьәләре буенча тәҗрибә уртаклашалар, аварияләр, һәлакәтләр һәм табигать бәла-казалары нәтиҗәләрен бетерүдә үзара ярдәм күрсәтешәләр, оператив хәлнең торышы

турында мәгълүмат алмашалар, җинаятьчелек, шул исәптән коррупциягә, терроргa, наркотик һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнешенә, корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч, агулы һәм радиоактив матдәләр белән законсыз операцияләргә каршы көрәш өлкәсендә хезмәттәшлек итәләр, төбәкара оешкан җинаятьчел формированиеләрне ачыклаганда һәм бетергәндә үзара хезмәттәшлек итәләр.

**7 статья**

Әлеге Килешү хезмәттәшлекнең анык өлкәләрендә ике яклы программалар, беркетмәләр һәм чаралар планнары, шулай ук килешүләр эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен нигез булып тора.

Үзара хезмәттәшлекне оештыру һәм координацияләү өчен кирәк булган саен Яклар тарафыннан эш төркемнәре, советлар, комиссияләр төзелергә мөмкин.

Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру буенча Якларның уртак эшчәнлеге ике яклы консультацияләр, эшлекле очрашулар, күргәзмәләр, ярминкәләр, семинарлар, конференцияләр һәм башка чаралар уздыру юлы белән тормышка ашырыла.

Әлеге Килешү нигезләмәләрен тормышка ашыруга булышлык итү, шулай ук аның нигезендә Яклар тарафыннан төзелгән (кул куелган) килешүләрне (беркетмәләрне) гамәлгә ашыру барышына контрольне тормышка ашыру өчен даими эшләүче координацияләү органы төзелә ала. Моннан тыш, кирәк булган саен, ике яклы консультацияләр яисә сөйләшүләр, шул исәптән иң югары дәрәҗәдәге сөйләшүләр уздырылырга мөмкин.

**8 статья**

Әлеге Килешү Якларның өченче яклар белән төзелгән килешүләре (шартнамәләр) буенча йөкләмәләренә кагылмый һәм шуңа күрә аларның өченче яклар алдындагы үзләренең йөкләмәләрен үтәү өчен киртә булып хезмәт итә алмый.

Әлеге Килешүнең нигезләмәләрен аңлатуда һәм куллануда яисә аларның гамәле чикләрен аңлауда мөмкин булган фикер аермасы, бәхәсле мәсьәләләр һәм аны гамәлгә ашыру барышында килеп чыгучы аерымлыклар Якларның консультацияләре яисә сөйләшүләре юлы белән хәл ителергә тиеш.

**9 статья**

Яклар Татарстан Республикасы һәм Мәскәү шәһәре арасындагы икътисадый, фәнни-техник һәм мәдәни өлкәләрдәге хезмәттәшлек принциплары турындагы 1996 елның 11 июнендәге Шартнамә әлеге Килешү үз көченә кергән көннән гамәлен туктата, дип таный.

**10 статья**

Әлеге Килешү аңа кул куйган мизгелдән үз көченә керә һәм 5 ел дәвамында гамәлдә була. Әгәр дә Якларның берсе дә башка Якка аның вакыты узганчыга кадәр Килешүнең гамәлен туктату турында язмача хәбәр итмәсә, Килешү автоматик рәвештә тагын бер елга озайтыла.

Килешү аның гамәле чорында Якларның язмача рәвештә белдерелгән үзара килешүе буенча теләсә кайсы вакытта өзелергә мөмкин. Килешү Якларның берсе тарафыннан аның гамәле туктатылу турында язмача хәбәр итүеннән соң 3 ай узгач өзелгән булып саналачак.

Әлеге Килешү Якларның үзара ризалыгы буенча өстәмә килешүләр белән тулыландырылырга һәм үзгәртелергә мөмкин. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр, әгәр алар язмача рәвештә башкарылса һәм Якларның вәкаләтле вәкилләре тарафынна имзаланса, гамәлдә була.

2011 елның «I2» мартында Казан шәһәрендә, һәркайсы рус һәм татар телләрендә, бер үк юридик көчкә ия булган, Якларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә башкарылды.

**Татарстан Республикасы өчен:**

**Татарстан Республикасы Президенты**

**Р.Н.Миңнеханов**

I2.03.2011

№ I0

**Мәскәү шәһәре өчен:**

**Мәскәү шәһәре Мэры**

**С.С.Собянин**

№ 77-490

I8.03.20II г.